СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески, Арский
муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 03 » август 2021 ел** **№ 31**

**Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 сентябрендәге 45 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында**

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары турында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Иске Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Иске Кырлай авыл җирлеге Советының 2017 елның 18 сентябрендәге 45 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазифаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районы *«Иске Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында* урнаштыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 3 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) бастырып чыгар у юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Лутфуллин